ЕЛАБУЖСКИЙ
ГОРОДСКОЙ
СОВЕТ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
ШӘҺӘР
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

14.11.2019 Алабуга шәһәре № 253

2013 елның 18 декабрендәге 174 санлы «Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында» гы Алабуга шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Бюджет законында үзгәрешләр нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр Советы

КАРАР кабул итте:

1. 2013 елның 18 декабрендәге 174 санлы «Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында»гы Алабуга шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында» Нигезләмәне яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карар, үз көченә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмә пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә:

27 маддәнең 3, 4 пунктлары; 28 маддәнең 1,2 пунктлары; 30 маддәнең 1,2,3,5,7,11 пунктлары; 33, 34 маддәләр 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә;

28 маддәнең 4 пункты; 30 маддәнең 6,8,9,12 пунктлары; 31 маддәнең 3 пункты 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисадый үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшмәкәрлекне үстерү бюджетара һәм җир-мөлкәт мөнәсәбәтләре мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары О.В. Михайлова